ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

29 11 2019 г. № 788

Капиталь төзелеш объектлары булмаган, законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексының 60 статьясындагы 2 пунктының 4 пунктчасы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә карар бирәм:

1. 1-нче кушымта нигезендә капиталь төзелеш объектлары булмаган, законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибен расларга.

2. 2-нче кушымта нигезендә капиталь төзелеш объектлары булмаган, законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау буенча Комиссия составын расларга.

3. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә һәм кулланучылар хезмәте күрсәтү бүлеге:

капиталь төзелеш объектлары булмаган законсыз урнаштырылган объектлар реестрын алып барырга;

Түбән Кама шәһәре территориясендә капиталь төзелеш объектлары булмаган, законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау буенча эшләрне оештырырга һәм билгеләнгән тәртиптә үткәрергә;

гамәлдәге закон нигезендә, Түбән Кама шәһәре территориясендә капиталь төзелеш объектлары булмаган, законсыз урнаштырылган объектларны демонтажлау, күчерү һәм саклауга вәкаләтле оешмаларны сайлап алуны гамәлгә ашырырга.

4. Әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.И.Беляевка йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 29-нчы ноябрь
788-нче номерлы карары белән расланган
1-нче кушымта

Капиталь төзелеш объектлары булмаган, законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Түбән Кама муниципаль районы милкендә булган җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрендә капиталь төзелеш объектлары булмаган. законсыз урнаштырлган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау белән бәйле чараларны тормышка ашыру буенча Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының, аның структур бүлекчәләренең эшчәнлеген регламентлаштыра.

2. Тәртип Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, Түбән Кама муниципаль районы Уставы һәм башка норматив хокукый актлар таләпләре нигезендә эшләнде.

3. Әлеге Тәртиптә түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

капиталь төзелеш объектлары булмаган законсыз урнаштырылган объектлар - капиталь төзелеш объектлары булмаган объектлар, шул исәптән стационар булмаган сәүдә объектлары (киосклар, павильоннар, барлык типтагы прицеплар (тонарлар), лотоклар, палаткалар, прилавкалар һәм тиз бозыла торган продукцияне һәм эчемлекләрне саклау һәм сату өчен суыту җиһазлары), капиталь булмаган корылмаларда җиһазландырылган җәмәгать туклануы объектлары (кафетерийлар, кабымлык һәм башка җәмәгать туклануы нокталары), шулай ук стационар җәмәгать туклануы объектлары каршында урнашкан сәүдә автоматлары һәм металл контейнерлар, Түбән Кама муниципаль районы милкендәге җир кишәрлекләрендә һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрендә урнашкан башка корылмалар, конструкцияләр, механизмнар (шул исәптән күчмә), мондый объектларны урнаштыру өчен нигез булып торган гамәлдәге законнарда каралган документлардан башка яисә мондый объектларны урнаштыру өчен нигез булып торган документларның гамәлдә булу вакыты чыккан очракта (алга таба - объект);

объектның хуҗасы - стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру шартнамәсе яисә объектка хокук билгеләүче башка документ нигезендә объектның хокук иясе булган заты;

объектны күчерү – объектны законсыз алып торган җир кишәрлегеннән җаваплы саклау урынына күчерү;

объектны сүтү - объектны инженер-техник тәэмин итү челтәрләреннән өзеп кую, кирәк булган очракта - объектны аерым өлешләргә сүтү, һәм аны урнашу һәм файдалану урыныннан җаваплы саклау урынына күчерү буенча гамәлләр;

капиталь төзелеш объектлары булмаган законсыз урнаштырылган объектлар реестры – (алга таба - объектлар реестры) - Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә һәм куллану хезмәтләре бүлеге тарафыннан формалаштырыла торган объектлар турында белешмәләр исемлеге (алга таба - Бүлек);

махсуслаштырылган оешма - законда билгеләнгән тәртиптә Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты белән төзелгән муниципаль контракт (шартнамә) нигезендә эш итүче объектларны демонтажлау, чыгару, җаваплы саклау буенча эш башкаручы оешма;

вазыйфаи затлар - капиталь төзелеш объектлары булмаган, законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау буенча Комиссия составына керүче Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре.

4. Әлеге Тәртипнең 1 пунктында каралган чараларны гамәлгә ашыру эшчәнлеген тормышка ашыру максатларында, Башкарма комитетта капиталь төзелеш объектлары булмаган, законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау буенча Комиссия (алга таба – Комиссия) төзелә.

Комиссияне комиссия рәисе җитәкли, ул комиссия эше белән җитәкчелек итә. Комиссия аның күпчелек әгъзалары булган очракта хокуклы. Комиссия карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

## 2. Капиталь төзелеш объектлары булмаган, законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау буенча эшләрне оештыру

5. Түбән Кама муниципаль районы территориясен тикшерү барышында законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау вазыйфаи зат тарафыннан башкарыла, шул исәптән, түбәндәге нигезләрдә:

1) Түбән Кама муниципаль районының тикшерү, күзәтчелек һәм хокук саклау органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан алынган мәгълүмат;

2) гражданнар, шәхси эшмәкәрләр, юридик затлар мөрәҗәгатьләре;

3) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүмат;

4) «Халык контроле» системасы аша халыктан алынган мәгълүмат.

5) башка мәгълүмат чыганаклары.

6. Законсыз урнаштырылган объектны ачыклау факты, объектны фотога төшереп, әлеге Тәртипкә 1-нче кушымта нигезендә, форма буенча акт белән рәсмиләштерелә.

7. Объектны тикшерү акты, аны төзү көненнән соң килгән бер эш көненнән дә соңга калмыйча, фотога төшергән материаллары кушып, объектны ачыклаган вазыйфаи зат тарафыннан объектлар реестрына тиешле язуны кертү Бүлегенә җибәрелә.

8. Объектлар реестры Бүлек тарафыннан аларны ачыклаган вазыйфаи затлардан кергән объектларны тикшерү актлары нигезендә формалаша. Актлардан мәгълүмат объектлар реестрына алар Бүлеккә кергән көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча кертелә.

Объектлар реестрында түбәндәгеләр турында мәгълүмат бар:

- объектны ачыклау урыны һәм аның исеме;
- объектның якынча габаритлары;
- объект хуҗасы булган юридик зат (исеме, юридик адресы, ИНН);
- объект хуҗасы булган шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (адресы, ИНН).

9. Объект хуҗасы билгеләнгән очракта, вазыйфаи зат тарафыннан обект ачыкланганда, объект хуҗасына (вәкаләтле вәкилгә), имза куйдырып, объектны ирекле демонтажлау турындагы күрсәтмә әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә тапшырыла, ә объект хуҗасы күрсәтмәне алудан баш тарткан очракта, тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта җибәрүе белән җибәрелә.

10. Объект хуҗасы билгеләнмәгән очракта, вазыйфаи зат, объектны ачыклаганда, күрсәтмәнең күчермәсен турыдан-туры объектта урнаштыра, бу хакта күрсәтмә бланкында билге ясала. Күрсәтмәнең күчермәләре фото һәм/яки видеога төшерү юлы белән теркәлә. Күрсәтелгән очракта вазыйфаи зат күрсәтмәне Бүлеккә күрсәтмәне һәм фотоматериалларны матбугат басмаларында бастырып чыгару һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тормышка ашыру өчен җибәрүне гамәлгә ашыра.

11. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге, әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны Бүлектән алган көннән соң биш эш көне эчендә аны матбугат басмаларына һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итә.

12. Объект хуҗасына объектны демонтажлау турында чыгарылган күрсәтмә турында хәбәр итү датасы булып, түбәндәге даталарның теләсә кайсы тора:

1) объект хуҗасын объектны демонтажлау турында күрсәтмә белән турыдан-туры таныштыру датасы;

2) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә ТР Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында демонтажлау турында күрсәтмә урнаштырылган көннән алып 5 көн узу;

3) почта бүлеге тарафыннан демонтажлау турында күрсәтмә алу турында хәбәрнамәне кире кайтару датасы (адресатның алудан баш тартуы турында тамга белән хат, күрсәтелгән адрес буенча адресатның булмавы турында тамга белән хат, саклау вакыты чыгу турында тамга белән хат).

13. Объект хуҗасы күрсәтмәдә күрсәтелгән демонтажлау турында күрсәтмә белән хәбәр ителгән көннән 14 көн эчендә, үз көчләре белән һәм үз хисабына объектны демонтажларга һәм законсыз урнашу урынын беренче халәткә китерергә тиеш.

Әгәр объект ирекле тәртиптә демонтажланган булса, объектны ачыклаган вазыйфаи зат законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау турындагы

күрсәтмәнең үтәлеше турында актны әлеге Тәртипнең 3-нче кушымтасы нигезендә форма буенча рәсмиләштерә, һәм аны биш эш көне эчендә Бүлеккә җибәрә.

### 3. Капиталь төзелеш объектлары булмаган объектны демонтажлау һәм күчерү тәртибе

14. Тәртипнең 12 пунктында каралган срок дәвамында объект хуҗасы тарафыннан ирекле тәртиптә объект демонтажланмаган очракта, Бүлек биш эш көне эчендә объектны демонтажлау һәм күчерү турында, объектны урнаштыруның хокуксыз булу фактын һәм объектны демонтажлау турында чыгарылган күрсәтмә турында объект хуҗасына әлеге Тәртипнең 11 пунктында билгеләнгән юллар белән хәбәр итү фактын раслаучы документларны, тикшерү актын, шулай ук күрсәтмәнең үтәлмәве турында актны (3-нче кушымта) теркәп, Башкарма комитет карары проектын әзерли башлый.

15. Демонтажлау турында Башкарма комитет карарында түбәндәге мәгълүмат күрсәтелергә тиеш:

- демонтажланырга тиешле объект;
- адрес ориентирларын күрсәтеп, объектның урнашу урыны;
- объектны демонтажлау нигезләре;
- объектның күчү урыны.

16. Башкарма комитетның объектны демонтажлау һәм күчерү турындагы карары нигезендә, Комиссия, махсус оешманы җәлеп итеп, объектны мәҗбүри демонтажлау эшләрен оештыра.

17. Объектларны демонтажлау, чыгару һәм саклау эшләрен гамәлгә ашыру буенча махсуслаштырылган оешманы билгеләү гамәлдәге закон таләпләре нигезендә башкарыла.

18. Мәҗбүри демонтажлау муниципаль бюджет акчалары хисабына һәм киләчәктә тотылган чыгымнарны объект хуҗасы исәбенә компенсацияләү юлы белән башкарыла.

19. Демонтаж барышында Комиссия тарафыннан әлеге Тәртипкә 4-нче кушымта нигезендә форма буенча демонтажлау турында акт төзелә.

Актта теркәлгән объект габаритлары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 15 апрелендәге 272 номерлы карары (алга таба – Кагыйдәләр) белән расланган Автомобиль транспортында йөк ташу кагыйдәләре белән билгеләнгән транспорт чараларының рөхсәт ителгән иң чик габаритларыннан артып киткән һәм Кагыйдәләрдә билгеләнгән зур габаритлы йөк критерийларына туры килгән очракта, объект сүтелгән рәвештә чыгарылырга тиеш.

20. Объектка ирекле керү мөмкинлеге булмаган очракта, демонтаж турында актта объектны ачу кирәклеге турында һәм комиссия әгъзаларының күпчелеге карары белән комиссия әгъзаларының берсе тарафыннан ачу процедурасының видеоязмасын беркетеп, соңгысы шаһитлар булганда (икедән да ким булмаган кызыксынмаган кеше) бергәләп ачыла.

21. Комиссия соратуы буенча, демонтажлау урынына, җәмәгать тәртибен саклау максатыннан, полиция хезмәткәрләре чакырыла. Полиция хезмәткәрләренең килмәве демонтажлау өчен киртә була алмый.

22. Демонтаж уздырганда, объектның, шулай ук аның эчендәге мөлкәтнең зыян күрү мөмкинлегенә максималь рәвештә юл куймаска кирәк. Махсуслаштырылган оешма вәкиле фикеренчә, объектны демонтажлау сүтүдән башка мөмкин булмаса, объектны детальләргә һәм башка элементларга аеруга юнәлдерелгән гамәлләр башкарыла, бу хакта Комиссия тарафыннан демонтаж турында актта билге ясала.

23. Объектны демонтажлаганда, анда булган мөлкәт әлеге Тәртипкә 5-нче кушымта нигезендә форма буенча Комиссия тарафыннан төзелә торган исемлеккә алынырга тиеш.

24. Объектны һәм анда булган мөлкәтне җаваплы саклау урынына алып чыкканда, милекне саклау максатыннан һәм киләчәктә аның югалуы турында дәгъваларны булдырмас өчен, демонтаж буенча Комиссия объектның ишегенә, тәрәзә капкачларына, люкларына һәм башка ачыла торган элементларына мөһер сугып чыга.

25. Демонтаж турындагы актта Комиссия, махсуслаштырылган оешма һәм башка затлар тарафыннан сүткәндә башкарылган барлык гамәлләр, объектның тасвирламасы һәм характеристикасы теркәлә. Демонтаж вакытында гамәлгә ашырыла торган фото һәм/яки видеофиксация материаллары демонтаж турында актның аерылгысыз өлеше булып тора. Демонтаж турындагы акт 2 нөсхәдә төзелә, шуларның берсе махсуслаштырылган оешмага тапшырыла, икенчесе Бүлектә кала.

26. Демонтаж, транспортлау, шулай ук төяү-бушату эшләрен тиешенчә башкармау аркасында объект хуҗасына китерелгән югалту, җитмәү яки зыян өчен махсуслаштырылган оешма җаваплы.

27. Бүлек объектны демонтажлау датасы һәм вакытын, объект хуҗасына объектны һәм анда булган мөлкәтне бирү тәртибен күрсәтеп, үткәрелгән демонтаж турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында объектны демонтажлаган көннән биш эш көне эчендә урнаштыруны оештыра.

## 4. Капиталь төзелеш объектлары булмаган объектларны саклау һәм кире кайтаруны тәэмин итү

28. Объект хуҗасы, үзенә җаваплы сакланышта булган объектны (аның өлеше элементларын) һәм демонтажланган объектта (алга таба – саклау предметы) булган мөлкәтне кире кайтару максатларында, Башкарма комитетка гариза белән мөрәҗәгать итә.

Гаризага демонтажланган объектка хокук билгеләүче документлар теркәлә.

29. Объектны һәм аның эчендәге мөлкәтне кире кайтару, объект хуҗасы тарафыннан Тәртипнең 27 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру шарты белән, кабул итү-тапшыру акты, мөлкәт исемлеге һәм фото - һәм/яки видеофиксация материаллары нигезендә Комиссия тарафыннан башкарыла.

30. Объектны җаваплы саклау мәйданчыгына күчергәннән соң 6 ай дәвамында объект хуҗасы объектны һәм анда булган мөлкәтне кире кайтаруны сорап мөрәҗәгать итмәсә, Түбән Кама муниципаль районы «Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе» МКУ йөзендә Башкарма комитет объектны һәм анда булган мөлкәтне хуҗасыз дип тану һәм Россия Федераиясенең гамәлдәге законнарында

каралган тәртиптә алга таба утильләштерү өчен әлеге объектка муниципаль милек хокукын тану турында законда билгеләнгән тәртиптә судка гариза белән мөрәҗәгать итә.

Объект хуҗасыннан объектка һәм анда булган мөлкәткә ия булу хокукыннан Башкарма комитет файдасына баш тарту турында язмача гариза кергән очракта, объектны һәм анда булган мөлкәтне хуҗасыз дип тану һәм әлеге объектка муниципаль милек хокукын тану турында суд карары таләп ителми.

31. Объектны утильләштерүне объектны утильләштерү эшләрен башкаруга контракт яки шартнамә буенча вәкаләтле оешма тәэмин итә.

32. Объектны демонтажлау, күчерүгә, җаваплы саклауга һәм утильләштерүгә бәйле чыгымнар объект хуҗасына йөкләнә.

33. Объект хуҗасы объектны һәм андагы мөлкәтне демонтажлау, күчерү, саклау һәм утильләштерү чыгымнарын компенсацияләүдән баш тарткан очракта, шулай ук тиешле таләпләрне белдергәннән соң, бер ай эчендә компенсация суммаларын түләмәгән очракта, әлеге чыгымнар Россия Федерациясе законнары нигезендә «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе» МКУ йөзендә суд тәртибендә объект хуҗасыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан эзләтеп алыналар.

34. Объектны һәм андагы мөлкәтне демонтажлау, күчерү, саклау һәм утильләштерү белән бәйле объект хуҗасыннан алына торган махсуслаштырылган оешма тарафыннан тотылган чыгымнар муниципаль бюджет керемен күчерелергә тиеш.

35. Объектларны демонтажлау барышында барлыкка килә торган бәхәсләр Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 29-нчы ноябрь
788-нче номерлы карары белән расланган
2-нче кушымта

Капиталь төзелеш объектлары булмаган,
законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау,
демонтажлау, күчерү һәм саклау буенча
комиссия составы

| | | |
|---|---|---|
| Беляев Р.И. | - | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкче-сенең беренче урынбасары, комиссия рәисе. |
| Комиссия әгъзалары: | | |
| Вафин М.Х. | - | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә һәм кулланучылар хезмәте күрсәтү бүлеге башлыгы; |
| Мингалиева А.Р. | - | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе башлыгы; |
| Гәрәев Т.Р. | - | «ДЕЗ» МБУ директорының җәмәгатьчелек белән эшләү буенча урынбасары; |
| Шипилов В.Н. | - | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы; |
| Наскаев А.Н. | - | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе башлыгы; |
| Ветлугин В.В. | - | Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама районы буенча идарәсе башлыгы. |

Капиталь төзелеш объектлары
булмаган, законсыз урнаштырылган
объектларны ачыклау, демонтажлау,
күчерү һәм саклау тәртибенә
1-нче кушымта

Капиталь төзелеш объекты булмаган объектны тикшерү
АКТЫ

№________ 2019 елның «_____ »________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(Ф.И.О., акт төзегән вазыйфаи затның вазыйфасы)

Әлеге актны шул турыда төзеде: түбәндәге адрес буенча

________________________________________________________________________

(капиталь төзелеш объекты булмаган объектның адресы һәм урнашу урыны)

________________________________________________________________________

Билгеләнде______________________________________________________________

(объектның тибы)

Ясалган_________________________________________________________________

Төсе____________________________________________________________________

Размеры ________________________________________________________________

Объектның кемнеке булуы турында мәгълүмат ______________________________

(физик яки юридик зат мәгълүматлары (ШЭ), адресы)

________________________________________________________________________

(күрсәтелә: стационар булмаган объект законлы (законсыз) урнаштырылган

Урнаштыру хокукына документлар юк:

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(объектны урнаштыру хокукы бирә торган булмаган документлар яисә мондый документларның гамәлдә булу срогы тәмамлану турында мәгълүмат, шулай ук объектны хокуксыз урнашкан объектларга кертергә мөмкинлек бирүче бүтән мәгълүмат (документлар) күрсәтелә)

Акт объект хуҗасы (вәкаләтле вәкил) катнашында төзелде:

________________________________________________________________________

(объект хуҗасының (вәкаләтле вәкилнең) Ф.И.О.) (Имза)

________________________________________________________________________

(Объект хуҗасы (вәкаләтле вәкил) имза салудан баш тарткан очракта, тиешле язма ясала)

Вазыйфаи затның имзасы

Кушымта: стационар булмаган объектның фотографиясе

Капиталь төзелеш объектлары
бул-маган, законсыз урнаштырылган
объектларны ачыклау, демонтажлау,
күчерү һәм саклау тәртибенә
2-нче кушымта

Капиталь төзелеш объекты булмаган,
законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау турында
күрсәтмә

№ ______ 2019 елның «____ »_____________

Кемгә: _________________________________________________________________
(гражданның (ШЭ) Ф.И.О. яисә юридик затның исеме һәм адресы)

_______________________________________________ вакыттан 14 көн эчендә
(әлеге күрсәтмә белән хәбәрнамә)
________________________________________________________________________
________________________________________________________адресы буенча урнашкан
________________________________________________________________________
(күрсәтелә: павильон, киоск һ.б.)

сезгә үз көчегез белән ирекле рәвештә һәм үз хисабыгызга демонтажларга кирәк.

Шулай ук объект хокуксыз урнашкан объектның урнашу урынын да беренчел хәлгә китерергә кирәк.
Әлеге күрсәтмәне үтәмәгән очракта, капиталь төзелеш объекты булмаган объектны демонтажлау, күчерү, саклау һәм утильләштерү буенча чыгымнарны сездән каплатып, мәҗбүри тәртиптә объект демонтажланачак.

Күрсәтмә белән таныштырылды____________________________________________
(вазыйфаи затның имзасы, имзаны расшифровкалау)
________________________________________________________________________

ТР Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
беренче урынбасары
(башка вәкаләтле зат)

Капиталь төзелеш объектлары
бул-маган, законсыз урнаштырылган
объектларны ачыклау, демонтажлау,
күчерү һәм саклау тәртибенә
3-нче кушымта

Капиталь төзелеш объекты булмаган,
законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау турында
күрсәтмәне үтәү (үтәмәү) турында
АКТ

№ _______ 2019 елның «_____»_______________

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(Ф.И.О., вазыйфаи затның вазыйфасы)

Әлеге актны шул турыда төзеде (-ләр):

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
түбәндәге адрес буенча законсыз урнаштыруны гамәлгә ашырган юридик яки физик зат (ШЭ) мәгълүматлары, адресы:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(күрсәтелә: капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау турында
20____ ____________ _____номерлы күрсәтмәне үтәде (үтәмәде)
______________________________________________________________________________
(күрсәтелә: объект демонтажланган (демонтажланмаган), чыгарылган (чыгарылмаган)

Кушымта:
- хокуксыз урнаштырылган объектның фотографиясе (объект урнаштырылган урын).

Вазыйфаи затларның имзасы (-лары):
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Капиталь төзелеш объектлары
булмаган, законсыз урнаштырылган
объектларны ачыклау, демонтажлау,
күчерү һәм саклау тәртибенә
4-нче кушымта

Капиталь төзелеш объекты булмаган,
законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау турында
АКТ

№_____ 2019 елның «____» ___________

Демонтажлауны (сүтүне) башлау: _________сәг._______ мин.
Демонтажлауны (сүтүне) тәмамлау: _______сәг. _______мин.
Капиталь төзелеш объектлары булмаган, законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау буенча Комиссия
түбәндәгеләр катнашында:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(Ф. И. О., вазыйфа)

____________________________________________________________адресы буенча
(объектны урнаштыру урыны адресы )
______________________________________________________________________________
________________________________________________________карамагында булган
(юридик яки физик зат мәгълүматлары (ШЭ), адресы)

Түбән Кама муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектны мәҗбүри демонтажлауны гамәлгә ашырдылар.»

Демонтаж законсыз урнаштырылган обектны демонтажлау турындагы күрсәтмәне үтәмәү турында 20___ елның «_____»____________ ____ номерлы акты белән расланган 20___ елның «____»_____________ ____ номерлы күрсәтмәнең үтәлмәве нигезендә башкарылган.

Демонтажлау вакытына объектның тышкы торышы
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Объектны ачу үткәрелде (үткәрелмәде) (тиешлесенең астына сызарга).

Объектны сүтү үткәрелде (үткәрелмәде) (тиешлесенең астына сызарга).
Объектны сүтмичә демонтажлау (сүтү) мөмкин булмауның сәбәпләре:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Мәҗбүри демонтажланган объект
____________________________________________________________________адресы
буенча җаваплы саклауга тапшырылды.

Махсуслаштырылган оешма вәкиле: ___________________________________________
(Ф.И.О., вазыйфа, имза)

Демонтажлау буенча Комиссия рәисе__________________________________________
(Ф.И.О., имза)

Башка катнашучы затлар:
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
(Ф.И.О., вазыйфа, имза)

Шаһитлар:
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
(Ф.И.О., паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны, имза)

Акт белән таныштырылды (таныштырылмады)
______________________________________________________________________________
(юридик яки физик зат (ШЭ) мәгълүматлары, имза)

Имза куюдан баш тартты
________________________________________________________________
(Демонтаж буенча Комиссия рәисенең Ф.И.О.)

Кушымта:
Түбән Кама муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш объекты булмаган, законсыз урнаштырылган объектны демонтажлаганда табылган мөлкәт һәм башка матди кыйммәтләр исемлеге, _____ биттә.

Капиталь төзелеш объектлары
булмаган, законсыз урнаштырылган
объектларны ачыклау, демонтажлау,
күчерү һәм саклау тәртибенә
5-нче кушымта

Капиталь төзелеш объекты булмаган, законсыз урнаштырылган объектны демонтажлаганда табылган мөлкәт һәм башка матди кыйммәтләр исемлеге

№_______ 2019 елның «_____ »___________

_____________________________________________________________ урнашкан
__________________________ ______________________________карамагында булган
(юридик яки физик зат (ШЭ) мәгълүматлары, адресы)

законсыз урнаштырылган объектны демонтажлауны гамәлгә ашырган вакытта түбәндәге матди кыйммәтләр табылды:

| т/с | Исеме | Саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | БАРЛЫГЫ | |

Объектны сүтеп демонтажлау үткәрү вакытында:

| т/с | Объектның состав материаллары | Үлчәме | Саны |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | БАРЛЫГЫ | | |

Демонтаж буенча Комиссия рәисе_______________________________________
(Ф.И.О., имза)

Башка катнашучы затлар:_____________________________________________
________________________________________________________________

(Ф.И.О., вазыйфа, имза)

Шаһитлар:

(Ф.И.О., паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны, имза)

Исемлек белән таныштырылды (таныштырылмады)

(юридик яки физик зат (ШЭ) мәгълүматлары, имза)

Имза куюдан баш тартты

(Демонтаж буенча Комиссия рәисенең Ф.И.О.)